ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2018 Казан ш. № 7-1/т

Китерү тимер юлларында «Тайд-фойл» фирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик максималь тарифлар билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Китерү тимер юлларында «Тайд-фойл» фирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик максималь тарифларны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
2018 елның 2 февралендәге 7-1/т номерлы
карарына кушымта

Китерү тимер юлларында «Тайд-фойл» фирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә чик максималь тарифлар

I бүлек. Чик максималь тарифлар

| т/б № | Хезмәт күрсәтү төре | Исәпләү берәмлеге | Тариф сумнарда (НДС исәпкә алынмаган) |
|---|---|---|---|
| 1. | 2 номерлы тимер юл участогы буенча 1,1 км арага йөк ташу | 1 тонна | 26,08 |
| 2. | 3 номерлы тимер юл участогы буенча 1,96 км арага йөк ташу | 1 тонна | 65,20 |
| 3. | 5 номерлы тимер юл участогы буенча 3,14 км арага йөк ташу | 1 тонна | 104,30 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган эшләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар, әмма "Чик максималь тарифлар" I бүлегендә каралган тарифлардан тыш, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган эшләргә һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар һәм җыемнар булдыру буенча методик тәкъдимнәр нигезендә якларның килешүе белән билгеләнә.

2. Йөк ташыган һәм төяү-бушату эшләрен башкарган өчен түләү заказчыдан чынбарлыкта ташылган йөк өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының билгеләнгән тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге